| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>422054, Республика Татарстан, Сабинский район,с.Большой Шинар, ул. Кооперативная,дом 36<br>тел. (84362) 41-2-11 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ<br>422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.12.2023

КАРАР
№31

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 ноябрендә кабул ителгән 22нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының риск индикаторлары турында 12.10.2023 елгы 01-54/7098 номерлы хатына таянып, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында" 08.11.2021 елда 22нче номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны кушымта буенча яңа редакциядә язарга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз кечен керә.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы A.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан
2023 елның 19нчы декабрендә кабул ителгән
31нче номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә
муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә
2нче кушымта

Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылу.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.